| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

09.03.2023 Казан ш № 144

Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымтада бирелә торган Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.
2. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе директоры Р.Р.Фәйзуллинга Регламент нигезләмәләренең тайпылышсыз үтәлүен тәэмин итәргә.
3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Н.В.Бутаевага йөкләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 09.03.2023 № 144 боерыгы белән расланды

## Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – дәүләт хезмәте).

1.2. Мөрәҗәгать итүче булып җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган һәм мөлкәт белән тәэмин ителү дәрәҗәсе «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кушымтасында билгеләнгән дәрәҗәдән кимрәк булган гаиләләрдә туган, уллыкка алынган, опекага алынган өч яшькә кадәрге балалары белән яшәү урыны яки тору урыны буенча бергә яши торган ата-ананың (законлы вәкилләрнең) берсе тора.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

### 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

#### 2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы

Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү (алга таба – дару чаралары сатып алуга түләү).

#### 2.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы аталышы

2.2.1. Дәүләт хезмәте «Республикасы матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Үзәк) тарафыннан мөрәҗәгать итүченең яшәгән урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Үзәк бүлекчәсендә (алга таба – Үзәк бүлекчәсе) күрсәтелә.

2.2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк (алга таба – күпфункцияле үзәк) аша гамәлгә ашырылмый.

## 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә форма буенча дару чараларын сатып алуга түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булып тора.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасында теркәлә.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә аны алу буенча сайланган ысул белән җибәрелә:

язма формада – почта адресы буенча;

электрон документ формасында – электрон почта адресы буенча;

телефонга смс-хәбәр итеп.

2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

2.3.4. дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар реквизитлары:

карар номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

гаризаның номеры һәм датасы;

мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

карар кабул итүгә вәкаләтле затның (алга таба – вәкаләтле зат) вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта).

## 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең срогы

2.4.1. Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 10 эш көне эчендә күрсәтелә.

Гариза һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар почта аша юллап җибәрелгән очракта, дәүләт хезмәте Үзәк бүлекчәсе тарафыннан гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән алып 10 эш көне эчендә күрсәтелә.

2.4.2. Элемтә хезмәтләре өчен дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү яисә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү срогы, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында соратып алына торган мәгълүматлар килмәгән очракта, 20 эш көненә озайтыла.

2.4.3. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) дару чаралары сатып алуга түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) турында карар кабул ителгән көнне башкарыла.

дару чаралары сатып алуга түләүне билгеләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында мөрәҗәгать итүчегә белдерү дару чаралары сатып алуга түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

дару чаралары сатып алуга түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү турында хәбәр юлланган мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, дару чаралары сатып алуга түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) карар күчермәсен бирү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

## 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында түбәндәгеләр урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

## 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырыла торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар:

1) кәгазь чыганакта шушы Регламентның 2 нче кушымтасы нигезендә форма буенча дару чараларын сатып алуга түләү билгеләү турында гариза.

2) мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының дару чаралары сатып алу өчен түләү билгеләү турында гариза бирү аена кадәрге соңгы 12 календарь айдагы керемнәрен раслаучы документлар:

һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү оешмаларында укучыларга, фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча көндезге формада белем алучы аспирантларга һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларының һәм фәнни оешмаларның дини белем бирү оешмаларында укучы дикторантларга түләнә торган стипендияләр һәм матди ярдәм турында белешмә;

гаилә әгъзалары ала торган алиментлар турында белешмә;

3) Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында хокуклары теркәлмәгән, гаилә әгъзалары милкендә булган күчемсез милек объектларына хокук билгели торган документларның күчермәләре;

4) чит ил дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

5) законнар нигезендә аның белән бергә яшәү мөмкин булмаган очракта, гаилә әгъзасында Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруның авыр формасы барлыгы турында белешмә, әгәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч

яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чараларын сатып алуга түләү турында» 2019 елның 3 декабрендәге 1095 номерлы карары белән расланган «Дару чаралары әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы федераль законның 55 статьясындагы 7 өлешендә каралган даруханә ассортиментының дару чараларын һәм башка товарларын сатып алуга түләүне билгеләгәндә гаиләнең җан башына туры килә торган керемен исәпләү тәртибенең 1.2 пунктында күрсәтелгән гражданнарның гаилә составына Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруның авыр формасы белән интегүче затлар керсә, бу авыру вакытында законнар нигезендә алар белән бергә яшәве мөмкин булмаса;

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Аны алмаштыра торган зат (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итүләрен раслый торган документны  күрсәтә.

Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан таныклана.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхес таныклаучы документ күчермәсеннән тыш) нотариус тарафыннан яисә документның төп нөсхәсен биргән орган (оешма, учреждение) тарафыннан таныкланган булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) (http://mtsz.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Гаризаны шулай ук Үзәк бүлегендә шәхсән кабул иткәндә электрон рәвештә тутырырга мөмкин, аңа мөрәҗәгать итүче, электрон рәвештә укыла торган имзадан файдаланып, кул куя.

2.6.2. Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәге мәгълүматлар алына:

яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итүче белән берлектә теркәлгән гражданнар турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

опека (попечительлек) билгеләү һәм опекунның (попечительнең) бала асрауга акча алуы турында («Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан);

дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү мәсьәләсен хәл иткәндә исәпкә алына торган физик затларның керемнәре турында (Федераль салым хезмәтеннән);

баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында (Федераль салым хезмәтеннән);

баланы тәрбиягә бала алучы гаиләгә тапшыру һәм тәрбиягә бала алучы ата-аналарга тиешле түләүнең суммалары турында («Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан);

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү яки ата-ана хокукларын чикләү турында («Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан);

күчемсез мөлкәт булуы турында (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтеннән (алга таба – Росреестр));

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм техниканың башка төрләре булуы турында ( Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

торак урынын билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип тану турында (җирле үзидарә органнарыннан);

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлар булуы (булмавы) турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтеннән)

шәхси счетның иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондыннан).

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге пунктта каралган документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

### 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре:

күчермәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән мөрәҗәгать иткәндә төп документларның күрсәтелмәве;

мөрәҗәгать итүченең документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган күчермәләрен почта аша җибәрүе;

мөрәҗәгать итүченең яисә мөрәҗәгать итүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш итәргә вәкаләтле затның мөрәҗәгать итүченең яшәгән урынына карамаган Үзәк бүлекчәсенә мөрәҗәгать итүе;

хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы булмаган комплект белән тапшырылуы.

### 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

баланың өч яшькә җитүе;

әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән гражданинның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәрен түләү буенча бурычлары булуы;

мөрәҗәгать итүче гаиләсенең мөлкәт белән тәэмин ителү дәрәҗәсенең «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтада билгеләнгән мөлкәти тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән артып китүе;

гаиләнең җан башына исәпләгәндә уртача керем күләменең дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү өчен мөрәҗәгать итү датасына Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләмен арттырып җибәрүе;

мөрәҗәгать итүченең яисә аның хезмәткә сәләтле гаилә әгъзаларының керемнәре булмау, 18 яшькә кадәрле биш һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрдән бердәнбер ата-ананың яки ата-ананың берсенең керемнәре булмаган очрактан тыш, ата-ананың икенчесе хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруы яисә пенсионер яки инвалид баланы (яки I төркем инвалидны яки дәвалау оешмасы бәяләмәсе буенча даими рәвештә ятлар каравына мохтаҗ булган яисә 80 яшенә җиткән өлкән кешене) карый торган зат, яки билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган зат булып торуы шарты белән;

мөрәҗәгать итүченең дару чаралары сатып алуга түләүнең алдагы билгеләнү чоры тәмамланганчы кадәр мөрәҗәгать итүе;

үзенә карата дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү турында гариза бирелә торган бала өчен түләүнең башка законлы вәкилгә билгеләнү фактының ачыклануы.

### 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

### 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.10.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

### 2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.11.1. Гариза һәм документлар килгән көнне.

2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-ноктал хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.12.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында,

дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) Үзәк бүлекчәсе хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар, шулай ук аудиоконтур күчермәләре булу.

2.12.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

## 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу күрсәткечләре:

Үзәк бүлекләре бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашкан булуы;

инвалидларга бүтән затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачау итүче киртәләрне җиңүдә ярдәм күрсәтү;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннарның кирәкле санда булуы;

Үзәкнең мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсендә, Министрлыкның рәсми сайтында алырга мөмкин.

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;

Үзәк бүлекчәсе белгечләренең әлеге Регламентны бозуына нигезле шикаятьләрнең булмавы.

2.13.4. Мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе белгечләре белән үзара хезмәттәшлеге:

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

гариза һәм документларны почта аша җибәргән очракта, турыдан-туры бәйләнешкә керү таләп ителми.

2.13.5. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлекчәсе белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.3. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла:

«Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасы;

«Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы.

2.14.4. Дәүләт хезмәте электрон формада һәм КФҮ аша күрсәтелми.

3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, шул исәптән гариза төзү өлешендә;

гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү;

дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар әзерләү;

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гаризаны төзү өлешендә дә.

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон аша, электрон почта һәм (яисә) хат белән Үзәк бүлегенә дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итә.

Үзәк бүлекчәсе белгече шәхсән, телефон аша, почта, электрон почта буенча, мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итү ысулына карап, мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча, гариза бланкын бирә һәм, зарурлык булганда, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән гаризаны төзү өлешендә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: консультация, тапшырылган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча кисәтүләр, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гаризаны төзү өлешендә.

3.3. Гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү турында гаризаны Үзәк бүлегенә, әлеге Регламентның 2.6.1 пунктына туры китереп,

документларны (документларның күчермәләрен) кушып тапшыра.

Гариза һәм документлар (документларның законнарда билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәләре) почта аша җибәрелергә мөмкин.

3.3.2. Үзәк бүлеге хезмәткәре дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган, шушы Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаганда, Үзәк бүлекчәсе белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм әлеге Регламентка 3 нче кушымтада күрсәтелгән гражданнар мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки;

мөрәҗәгать итүчегә гаризаны һәм документларны кабул итү датасы, беркетелгән керү номеры (мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта) турында тамгалап язу тапшыра, гариза почтадан һәм (яки), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелгәндә, – гаризаны теркәү датасы һәм беркетелгән керү номеры турында хәбәр җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булган очракта (шәхсән мөрәҗәгать иткәндә), Үзәк бүлекчәсе белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре турында телдән хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, барлык документларны аңа кайтарып бирә. Гаризаны һәм документларны почта аша һәм (яисә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән алганда, Үзәк бүлеге белгече гаризаны һәм документларны, документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту сәбәпләрен язмача аңлатып, кайтарып бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

шәхсән кабул иткәндә яисә гариза һәм документлар почта аша килгәндә – гариза һәм документлар алынган көнне.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән документлар, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәү язуы, документларны кабул итү турында язу яисә мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирелгән документлар, мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту турында телдән (язмача) белдерү.

3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга (оешмаларга) җибәрү

3.4.1. Үзәк бүлекчәсендә теркәлгән гариза рәсми мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып тора.

3.4.2. Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне ала:

банктан яисә Үзәк белән үзара хезмәттәшлек турында килешү төзегән башка кредит оешмасыннан блокка куелган максатчан шәхси счет реквизитлары турында (мөрәҗәгать итүче өч яшькә кадәрге баланың ата-анасы (законлы вәкиле) булган очракта)(хезмәттәшлек турында килешү төзелгән кредит оешмасыннан);

баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында (Федераль салым хезмәтеннән).

3.4.3. Дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлекчәсендә

булмаганда, Үзәк бүлекчәсе хезмәткәре электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында гарызнамәләр җибәрә:

яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итүче белән берлектә теркәлгән гражданнар турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына);

опека (попечительлек) билгеләү һәм опекунның (попечительнең) бала асрауга акча алуы турында («Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасына);

дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү мәсьәләсен хәл иткәндә исәпкә алына торган физик затларның керемнәре турында (Федераль салым хезмәтенә);

баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында (Федераль салым хезмәтенә);

баланы тәрбиягә бала алучы гаиләгә тапшыру һәм тәрбиягә бала алучы ата-аналарга тиешле түләүнең суммалары турында («Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасына);

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү яки ата-ана хокукларын чикләү турында («Опека һәм попечительлек» автоматлаштырылган мәгълүмат системасына);

күчемсез мөлкәт булуы турында (Росреестрга);

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм техниканың башка төрләре булуы турында (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына);

торак урынын билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип тану турында (җирле үзидарә органнарына);

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычлар булуы (булмавы) турында белешмәләр (Федераль салым хезмәтенә).

шәхси счетның иминият номеры турында  (Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фондына).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны һәм документларны кабул иткән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать.

Әлеге органнарга ведомствоара мәгълүмат сорау турында рәсми мөрәҗәгать ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең региональ системаларын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә  дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

3.4.4. Әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында каралган белешмәләр ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә  ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

3.4.4. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

1) сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

2) ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында каралган белешмәләр әлеге белешмәләрне үз эченә алган документлар белән эш итүче органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясының 3 өлеше нигезендә ведомствоара гаризаларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр, сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки аларда булган белешмәләрне) алу.

Белешмәләрне куллануның максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.

3.5. Дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар әзерләү.

3.5.1. Үзәк бүлекчәсе белгече әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара хезмәттәшлек итү органнарыннан алынган белешмәләр һәм мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:P409

мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле буларак катнашучы затның яисә алар тарафыннан вәкаләт бирелгән затның вәкаләтләрен тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә форма буенча дару чараларын сатып алуга түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проектын рәсмиләштерә;

дару чараларын сатып алуга түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) электрон рәвештәге карар проектын имза салу өчен Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар рәсми мөрәҗәгатьләргә җавап килгән көннән соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла, ләкин гаризаны теркәгән көннән соң җиде эш көнненән дә соңга калмыйча.

Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында соратып алына торган мәгълүматлар килмәгән очракта, дару чараларын сатып алуга түләү билгеләү яисә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү срогы 20 эш көненә арттырыла. Үзәк бүлекчәсе белгече мөрәҗәгать итүчегә дару чараларын сатып алуга түләү билгеләү яисә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү вакытын озайту хакында дару чараларын сатып алуга түләү билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән

хәбәр итә.

Процедураларның нәтиҗәсе: дару чараларын сатып алуга түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында электрон рәвештә карар проекты, дару чараларын сатып алуга түләү билгеләү турында яисә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү вакытын арттыру турында белдерү.

3.5.2. Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе дару чараларын сатып алуга түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында электрон рәвештәге карар проектын карый һәм электрон санлы имза белән имзалап, Үзәк бүлекчәсе белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дару чараларын сатып алуга түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проектын имзалау җибәргәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) турында Үзәк бүлекчәсе белгеченә җибәрелгән һәм имзаланган карар.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

Үзәк бүлекчәсе белгече дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүчегә гаризада мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән ысул белән (язмача формада шәхсән яисә почта адресы буенча, электрон почта адресы буенча көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында, телефонга смс-хәбәр җибәрү юлы белән) бирә (җибәрә).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дару чараларын сатып алуга түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү көненнән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: дару чараларын сатып алуга түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) турында кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү, гаризада күрсәтелгән ысул белән дару чараларын сатып алуга түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) турында карар җибәрү.

3.8. Техник хаталарны төзәтү

Техник хатаны төзәтү мөрәҗәгать итүче тарафыннан, аңа дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 4 нче кушымтасына ярашлы форма буенча гариза бирелгәндә гамәлгә ашырыла.

3.8.1. Үзәк бүлеге белгече:

техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки;

Дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарны үзгәртеп рәсмиләштерә;

дару чараларын сатып алуга түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) яңадан рәсмиләштерелгән карар проектын электрон формада имза салу өчен Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән һәм

теркәлгән гариза, Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә имзалау өчен юлланган дару чараларын сатып алуга түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән, электрон рәвештәге карар.

3.8.2. Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе дару чараларын сатып алуга түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) яңадан рәсмиләштерелгән карарга электрон цифрлы имза куя һәм аны Үзәк бүлекчәсе белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура карар проекты имза салу өчен җибәрелгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан имзаланган дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) яңадан рәсмиләштерелгән карар.

3.8.3. Үзәк бүлекчәсе белгече гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп) хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дару чараларын сатып алуга түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар Үзәк бүлекчәсе белгеченә җибәрелгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: дару чараларын сатып алуга түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү, гаризада күрсәтелгән ысул белән дару чараларын сатып алуга түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) турында карар җибәрү.

## 4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Әлеге Регламентның административ процедураларында билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеген үтәүне агымдагы контрольдә тоту Үзәк бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан әлеге Регламентның нигезләмәләрен саклау һәм үтәү буенча тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла. Үзәк бүлеге җитәкчесе тарафыннан карарлар кабул ителүне көндәлек тикшереп торуны оештыру тәртибен һәм рәвешләрен Үзәк директоры билгели.

Агымдагы контрольлек даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.2. Әлеге Регламент үтәлешен контрольдә тоту әлеге контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле Министрлык Аппараты бүлегенең һәм Татарстан Республикасы муниципаль районында һәм шәһәр округында Министрлыкның социаль яклау идарәсенең (бүлегенең) вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла, аларның вәкаләтләре Министрлыкның структур бүлекчәсе турындагы нигезләмәдә һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи регламентлары белән билгеләнә.

Белешмә телефоннар, дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр Министрлыкның рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru) урнаштырыла.

4.3. Әлеге Регламент үтәлешен контрольдә тоту дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләргә тикшерүләр үткәрүне, карарлар кабул итүне, җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре

түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.4. Әлеге Регламент үтәлешенә планнан тыш тикшерү уздыру турындагы карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) мөрәҗәгать итүчеләр Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавының) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.5. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, әлеге административ регламентны үтәү өчен җаваплы булып, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.6. Әлеге Регламент үтәлешен контрольдә тоту гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Үзәк, Үзәк бүлекчәсе эшчәнлегенең ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм ышанычлы мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның, КФҮ, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр судка кадәр тәртиптә Үзәк бүлекчәсенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Үзәк бүлеге җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Үзәк җитәкчесенә тапшырыла.

Үзәк җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка тапшырыла.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны, 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгатьне теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тарту очрагында;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартылганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) дәүләт хезмәте күрсәтүче орган (учреждение), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат (учреждение хезмәткәре) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән чоры бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәткәренең (учреждение хезмәткәренең), дәүләт хезмәте күрсәтүче орган (учреждение) җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять язмача формада кәгазьдә яисә электрон формада тапшырыла.

Дәүләт хезмәтеннән файдаланучылар тарафыннан шикаять почта буенча, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның (http://mtsz.tatarstan.ru) рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (https://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене

шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган  почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.6.1. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган (учреждение) тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук

китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.6.2. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.7. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, учреждение хезмәткәре булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрәләр.

Өч яшькә кадәрге балалары
булган гаиләләргә дару
чаралары сатып алуга түләү
билгеләү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 1 нче кушымта

Формасы

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре)
республика үзәге» ДКУ №_____ бүлекчәсе

___________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү турында карар

№ ____ ______________ 20__ ел.

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) _____
___________________________________________________________________________

Мөрәҗәгать итүченең адресы ______________________________________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алу өчен түләү турында» 2019 елның 3 декабрендәге 1095 номерлы карары нигезендә дару чаралары сатып алу өчен түбәндәгегә түләү билгеләргә __________________________________________
___________________________________________________________________________
(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта))

10 000 сум күләмендә.

Билгеләү вакыты: __________ башлап _________________ кадәр

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе

җитәкчесе_________________________________________ ______________________
_______________
муниципаль район (шәһәр округы)) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (имза)
(соңгысы – булган очракта)

Мөһер урыны
«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе белгече

_________________________________________ _____________________ ________________
муниципаль район (шәһәр округы)) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (имза)
соңгысы – булган очракта)

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителде:
язма формада – почта адресы буенча ______________________
әлеге телефонга смс-хәбәр итеп ____________________________________________
(телефон номеры)
электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресы буенча __________________________________
(электрон почта адресы)

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ № ___ бүлегенә
____________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Дару чаралары сатып алуга түләүне билгеләүдән баш тарту турында карар

№ ___ __________ 20__ ел.

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) _____
________________________________________________________________________________.
Мөрәҗәгать итүченең адресы: __________________________________________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алу өчен түләү турында» 2019 елның 3 декабрендәге 1095 номерлы карары нигезендә дару чаралары сатып алу өчен түбәндәгегә түләү билгеләүдән баш тартырга _____________________________________
________________________________________________________________________________
(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))
Баш тарту сәбәбе: ______________________________________________________________

«Республика матди ярдәм

(компенсация түләүләре) үзәге»
ДКУ № ___ бүлеге мөдире

_________________________ ___________ ___________________ ______________
муниципаль район (шәһәр округы)) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (имза)
(соңгысы булган очракта)

Мөһер урыны
№____ бүлекчә белгече
«Матди ярдәм (компенсация
түләүләре) республика үзәге»
ДКУ

____________________________________ ___________________ ______________
муниципаль район (шәһәр округы)) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (имза)
(соңгысы булган очракта)

Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителде:
язма формада – почта адресы буенча ____________________
әлеге телефонга смс-хәбәр итеп _______________________________________
(телефон номеры)
электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресы буенча ______________________________
(электрон почта адресы)

Өч яшькә кадәрге балалары
булган гаиләләргә дару чаралары
сатып алуга түләү билгеләү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
2 нче кушымта

Формасы

«Республика матди ярдәм (компенсация
түләүләре) үзәге» ДКУ № ___ бүлекчәсенә
_______________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

ГАРИЗА № ___
_________ 20__ ел.

Мин ___________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең, ышанычлы затның яисә законлы вәкилнең фамилиясе, исеме,
атасының исеме (соңгысы - булган очракта) тулысынча)

| Шәхес таныклаучы документ атамасы | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

яши торган адресы:
_______________________________________________________________________________,
(индексын күрсәтеп, мөрәҗәгать итүченең почта адресы, телефоны, электрон почта адресы)

түбәндәгеләргә нигезләнеп эш итәм:
_______________________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат мәнфәгатьләрендә эш итүен раслый торган документларның реквизитлары, ышанычлы зат яисә законлы вәкил мөрәҗәгать иткән очракта)

Мөрәҗәгать итүченең хосусый шәхси счет номеры _____________

Билгеләвегезне сорыйм ___________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) тулысынча күрсәтелә), яши торган адресы:

_______________________________________________________________________________
(почта индексы, мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлү адресы)

_______________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ реквизитлары)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алу өчен түләү турында» 2019 елның 3 декабрендәге 1095 номерлы карары нигезендә дару чаралары сатып алу өчен түләү

_______________________________________________________________________________
(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) тулысынча

Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| | Документларның аталышы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Гариза бирү көненә сезнең турында яки гаилә әгъзаларыгыз турында түбәндәге расламаларның берсе яки берничә дөрес булып торса, тиешле шакмакка тамга куегыз:

☐ Сезнең милектә яисә сезнең гаилә әгъзалары милегендә гражданнар белән бер фатирда бергәләп яшәве мөмкин булмаган, катлаулы хроник авыру төрләренең Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган исемлегендә каралган хроник чирнең авыр формасыннан интегүче гаилә әгъзасы яши торган, «торак» билгеләнешендәге бүлмә (аның бер өлеше) бар;

☐ Сез яисә сезнең гаилә әгъзалары үз милкендә хокуклары Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән, гаилә әгъзалары милегендә торган күчемсез милек объектларына ия;

☐ Сез яки сезнең гаилә әгъзалары җан башына уртача кереме исәпләнгән чорда алимент алган;

☐ Сез һәм Сезнең гаилә әгъзалары һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү оешмаларында укучыларга, фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча көндезге формада белем алучы аспирантларга һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларының һәм фәнни оешмаларның дини белем бирү оешмаларында укучы дикторантларга түләнә торган стипендияләр һәм матди ярдәм алган.

Түләү алучының гаилә составы:

| | Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта) (туган көне) | Туганлык мөнәсәбәтләре | Паспорт (бала туу турында таныклык) реквизитлары | Кирәк-лесен билге-ләргә * |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

--------------------------------

* дәүләт хезмәте билгеләнә торган балалар билгеләнә.

Гаризада күрсәтелгән балаларның (баланың) тулысынча дәүләт тәэминатында тормавы хакында раслыйм, шулай ук аларга (аңа) карата

________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителмәгәнмен, ата-ана хокукларында чикләнмәгәнмен

____________ ___________________________________
(мөрәҗәгать итүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең имзасы, тулы имзасы)

________________________________________________________________________
(балага опека билгеләнгәндә опека билгеләгән органның исемен һәм урнашу урынын күрсәтергә)

Тапшырылган белешмәләрнең төгәл булуы, шулай ук аларны үз эченә алган документларның хаклыгы өчен җаваплы булам _________________________
(мөрәҗәгать итүче, ышанычлы зат яки законлы вәкил имзасы тулысынча)

Мәгълүмат алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту)

турында да, риза:
әлеге адрес буенча язмача формада___________________________________
әлеге телефонга смс-хәбәр итеп _______________________________________
(телефон номеры)
электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресына _____________________________________
(электрон почта адресы)

Гариза һәм документлар кабул ителде _______ _________ _______________________
(дата, белгечнең имзасы, тулы имзасы)

___________________________________________________________________________
Өзү линиясе
Язу-белдерү

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү номеры _____________
Документлар саны ____ данә, __ биттә
Документларны кабул итте ___________ _________ ____________________ ___________
(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)

Өч яшькә кадәрге балалары
булган гаиләләргә дару чаралары
сатып алуга түләү билгеләү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
3 нче кушымта

Формасы

Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү
ЖУРНАЛЫ

| т/с | Мөрәҗәгать итү датасы | Мөрәҗәгать номеры | Гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) | Адресы | Мөрәҗәгать итү сәбәпләре | Мөрәҗәгать нәтиҗәләре | Сәбәпләре күрсәтелмәгән мөрәҗәгать нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

Өч яшькә кадәрге балалары булган
гаиләләргә дару чаралары сатып
алуга түләү билгеләү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
4 нче кушымта

Формасы

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ № _____ бүлекчәсе

_______________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Техник хата төзәтү турында гариза

Мин,____________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) тулысынча күрсәтелә)

яши торган адрес: _______________________________________________________
_________________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)

_________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документның аталышы, аның сериясе, номеры, бирелү датасы,

_________________________________________________________________________.
документны биргән орган атамасы)

техник хатаны төзәтүне сорыйм ___________________________________________
_________________________________________________________________________,

җибәрелгән (кирәклесе астына сызарга):

дару чараларын сатып алуга түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарда җибәрелгән: ______________ № ______________.
(карар датасы) (карар номеры)

Үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны алуга риза:

_________________________________________________________________________,
(язмача, телефон аша, смс-хәбәр белән, электрон почта аша)

«__» ________ 20__ ел. ______________________ ______________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имза)